КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 30 июль г.Казань № 554

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт командировкаларына бәйле булган һәм башка урынга эшкә күчкәндәге чыгымнарны каплау тәртибе һәм күләмнәре турында» 2019 ел, 20 май, 410 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 29 декабрь, 1726 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт командировкаларына бәйле һәм башка җирлеккә күчкәндәге чыгымнарны каплау тәртибе һәм күләмнәре турында»;

1 пунктның икенче абзацында «хезмәткәрләргә» сүзенә кадәр «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе» сүзләрен өстәргә;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенә һәм «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесенә чыгымнарны финанслауны әлеге карар нигезендә «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында һәм аларны карап тотуга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетында каралган акчалар исәбеннән гамәлгә ашырырга.»;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт

командировкаларына бәйле булган һәм башка урынга эшкә күчкәндәге чыгымнарны каплау тәртибе һәм күләмнәре турында нигезләмәдә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе һәм «Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды» дәүләт учреждениесе хезмәткәрләренә хезмәт командировкаларына бәйле чыгымнарны каплау тәртибе һәм күләмнәре турында нигезләмә»;

1 пунктта «хезмәткәрләргә» сүзенә кадәр «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе (алга таба - Фәннәр академиясе)» сүзләрен өстәргә;

2 пунктның «д» пунктчасында «Территориаль фонд директоры» сүзләрен «Фәннәр академиясе президенты һәм Территориаль фонд директоры (алга таба - җитәкчеләр)» сүзләренә алмаштырырга;

5 пунктның «а» пунктчасындагы беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) җитәкчегә:»;

10 пунктта «Территориаль фонд директорының» сүзләрен «җитәкчесенең» сүзенә, «аны карап тотуга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетында каралган» сүзләрен «карауга каралган тиешенчә Фәннәр академиясенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетында» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның «а» пунктчасында «директорга» сүзен «җитәкчегә» сүзенә алмаштырырга;

14 пунктның икенче абзацында «Территориаль фонд директоры» сүзләрен «җитәкче» сүзенә алмаштырырга;

20 пунктның икенче абзацында «директор» сүзен «җитәкче» сүзенә алмаштырырга;

$21^1$ пунктта:

«в» пунктчасында «Территориаль фонд директоры» сүзләрен «җитәкче» сүзенә алмаштырырга;

«г» пунктчасының икенче абзацында «Территориаль фонд директоры» сүзләрен «җитәкче» сүзенә алмаштырырга;

23 пунктта «Территориаль фонд директоры» сүзләрен «җитәкче» сүзенә алмаштырырга;

24 пунктта «Территориаль фонд директорының» сүзләрен «җитәкчесенең» сүзенә, «аны карап тотуга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетында каралган» сүзләрен «карауга каралган тиешенчә Фәннәр академиясенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетында» сүзләренә алмаштырырга;

25 пунктта:

«хезмәткәрләр» сүзенә кадәр «Фәннәр академиясе» сүзләрен өстәргә;

«аны карап тотуга Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетында каралган» сүзләрен «карауга каралган тиешенчә

Фәннәр академиясенең финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетында» сүзләренә алмаштырырга;

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт органнары хезмәткәрләренә һәм Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт командировкаларына бәйле чыгымнарны каплау турында» 2024 ел, 25 октябрь, 921 нче карарына, 6 пунктта «хезмәткәрләр» сүзенә кадәр «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе» сүзләрен өстәп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин